# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлегенең Илнәт торак пунктында 2025 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү турында**

16.11.2024 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлеге башлыгының “Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлегенең Илнәт торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында” 2024 елның 2 ноябрендәге 12 номерлы карары нигезендә. КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2025 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районының Монашево авыл җирлегенең Илнәт авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I-II төркем инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 1000 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә:

1) Илнәт торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны кардан чистарту) ;

2) Илнәт торак пунктында урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (энергияне саклый торган яктырткычларны һәм урамнарны яктырту лампаларын сатып алу һәм алмаштыру, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү));

3) Илнәт торак пунктындагы каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү (чүп контейнерлары сатып алу)?»

2. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 10 көн эчендә Монашево авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында “Монашево авыл җирлеге” бүлегендә (http://mendeleevsk.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Менделеевск муниципаль районы
Монашево авыл җирлеге башлыгы Р.Ф.Иосифов